СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 48 от 24.02.2021

на № ______ от __________

# КАРАР

2021 нче елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы милкендәге һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 нче елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы милкендәге һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Әлеге карарны “Интернет” челтәрендә Россия Федерациясенең www.torgi.gov.ru рәсми сайтында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru. рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2021 елның 24 февралендәге
48 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

# 2021 нче елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы милкендәге һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

## 1 Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2021 елның беренче яртыеллыгына Саба муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне (алга таба-муниципаль милек) хосусыйлаштыруның әлеге фараз планы (программасы) “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Саба муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру 2021 елның беренче яртыеллыгында муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын карап тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан кергән бюджет кытлыгын каплау чыганакларын формалаштыруга юнәлдерелгән.

1.3. “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны аукционда яисә конкурста сату юлы белән һәм законда каралган башка ысуллар белән башкару күздә тотыла.

1.4. 2021 елның беренче яртыеллыгында муниципаль милектәге муниципаль мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

1.5. 2021 елның беренче яртыеллыгында хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге 1 нче таблицада күрсәтелгән:

1 Таблица

| № п/п | Объект исеме | Урнашу урыны | Мәйдан, кв.м. | Хосусыйлаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кадастр номеры 16:35:040101:181 булган янәшәдәге җир кишәрлеге белән, кадастр номеры 16:35:040101:506 булган “Административ бина” торак булмаган бинасы | Татарстан Республикасы, Саба районы, Олы Шыңар авылы, Кооператив урамы, 32 йорт | 224,5 | беренче яртыеллык |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Кадастр номеры 16:35:140109:451 булган янәшәдәге җир кишәрлеге белән, кадастр номеры 16:35:140109:75 булган “Депо бинасы” | Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш. т. б., Төзүчеләр урамы, 2 йорт | 1726,2 | беренче яртыеллык |

1.6. Муниципаль милектәге муниципаль унитар предприятиеләрне һәм акцияләрне 2021 елның беренче яртыеллыгында хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

1.7. Муниципаль мөлкәтне, шул исәптән мондый мөлкәтне сатып алучы заттан читләштереп сату гамәлгә ашырыла торган мөлкәтне, шундый мөлкәте булган һәм алардан файдалану өчен кирәкле җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турындагы карар Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

**2 Бүлек . Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү**

1.8. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә тапшыру һәм киң реклама белән тәэмин итү максатларында, Саба муниципаль районы, әлеге прогноз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.